ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**2019 ел, « 21 » август** **№ 133**

**Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетның 2016 елның 27 декабрендәге «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында "**

**41 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2006 елның 27 июлендәге "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында”149-ФЗ номерлы федераль законга, 2013 елның 5 апрелендәге “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар,эшләр, хезмәт күрсәтүләр, сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында“ 44-ФЗ номерлы федераль законның 4 нче статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 28 ноябрендәге "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр, сатып алу өлкәсендә төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына бердәм таләпләр турында " 1091 номерлы карарына яраклаштыру максатыннан Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Татарстан республикасы Арча муниципаль районы “Сеҗе авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 47 нче номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.7 пунктының 2 пунктчасының 5 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 3.7 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

3) контракт системасы турында Федераль законда каралган электрон документларга кул кую өчен, контракт системасы турында Федераль законда каралган электрон имзадан (алга таба - электрон имза) файдалану;

1.3.3.7 пунктының 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. 4.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Региональ һәм муниципаль системалардан бердәм мәгълүмати системага тапшырыла торган мәгълүмат һәм документлар контракт системасы турында Федераль законда каралган электрон имза белән имзалана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карар игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам

Сеҗе авыл җирлеге башкарма

комитеты җитәкчесе Г.М.Гибадуллина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ СИЗИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
ИНН 1609012741